ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 декабрь 2024 ел № 8730

Башкарма комитетның «Даими муниципаль маршрутлар буенча шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2024 елның 26 августындагы 5531 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Даими муниципаль маршрутлар буенча шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 2024 елның 26 августындагы 5531 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «30 893,38» цифрларын «36 074,77» цифрларына алмаштырырга;

2) даими муниципаль маршрутлар буенча шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә 22 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктча өстәргә:

«4) субсидия күләмен киметү яки арттыру мәсьәләләрен карап тикшерү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ